**СОВЕТ**
**НОВОШЕШМИНСКОГО**
**МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**
**РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
ул. Советская, д.80,
с. Новошешминск,423190

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ЯҢА ЧИШМӘ**
**МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**СОВЕТЫ**
Совет урамы, 80,
Яңа Чишмә авылы, 423190

тел.: (8-84348) 2-31-00, факс: (8-84348) 2-20-22, chishma@tatar.ru

Татарстан Республикасы
Яңа Чишмә муниципаль районы Советы
КАРАРЫ

2024 елның «05» сентябреннән №48-370

Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советының 2021 елның 29 декабрендәге 17-134 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитеты структурасына һәм чик санына үзгәрешләр кертү турында

«Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнары һәм Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары арасында шәһәр төзелеше эшчәнлеге өлкәсендәге вәкаләтләрне яңадан бүлү турында» 2023 елның 23 декабрендәге 131-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, «Татарстан Республикасы төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгы структурасын раслау турында» Татарстан Республикасы Президенты Указына һәм «Татарстан Республикасы дәүләт органнарында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфаларының гомуми санын раслау турында» Татарстан Республикасы Президенты Указына үзгәрешләр кертү хакында» 2023 елның 27 декабрендәге 916 номерлы Татарстан РеспубликасыРәисе Указы белән, «Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы мәсьәләләре» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2005 елның 06 июлендәге 313 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2023 елның 29 декабрендәге 1721 номерлы карары нигезендә Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советы

КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитетының төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык бүлеге әйдәүче белгече штатын кыскартырга.

2. Кушымтага нигезләнеп, «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең җирле үзидарә органнары хезмәткәрләренең структурасын һәм иң чик санын раслау турында» 2021 елның 29 декабрендәге 17-134 номерлы Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советы карарына «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитетының структурасы һәм аның чик саны» дигән 2 нче кушымтаны яңа редакциядә бәян итәргә.

3. Әлеге карарны «Интернет»мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында https://pravo.tatarstan.ru, Яңа

Чишмә муниципаль районының рәсми сайтында https://novosheshminsk.tatarstan.ru/ бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советының законлылык, хокук тәртибе һәм җирлекләрнең вәкиллекле органнары белән хезмәттәшлек буенча даими депутат комиссиясенә йөкләргә.

Яңа Чишмә
муниципаль районы Башлыгы

В. М. Козлов

2 нче кушымта
Татарстан Республикасы Яңа Чишмә
муниципаль районы Советының
муниципального района
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
2021 елның 29 декабрендәге 17-137 нче
номерлы карарына
(түбәндәге Татарстан Республикасы Яңа
Чишмә муниципаль районы Советының
түбәндәге карарлары редакциясендә:
2022 елның 08 апрелендәге 20-164
номерлы;
2022 елның 03 августындагы 25-193
номерлы;
2022 елның 08 сентябрендәге 26-204
номерлы;
2022 елның 12 декабрендәге 29-230
номерлы;
2024 елның 08 сентябрендәге 48-370
номерлы;

Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитеты структурасы һәм чик саны
Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитетының
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

| № т/б | Вазифа атамасы | Берәмлекләр саны |
|---|---|---|
| 1. | Җитәкче | 1 |
| 2. | Җитәкченең беренче урынбасары (икътисад буенча) | 1 |
| 3. | Җитәкче урынбасары (социаль мәсьәләләр буенча) | 1 |
| 4. | Җитәкче урынбасары (инфраструктур үсеш буенча) | 1 |
| 5. | Эшләр белән идарә итүче | 1 |
| 6. | Җитәкче ярдәмчесе (мобилизация эшләре буенча) | 1 |
| | Мәгариф бүлеге | |
| 7. | Башлык | 1 |
| 8. | Башлык урынбасары | 1 |

| | | |
|---|---|---|
| 9. | Баш белгеч | 1 |
| | Яшьләр эшләре, спорт һәм туризм бүлеге | |
| 10. | Башлык | 1 |
| 11. | Баш белгеч | 1 |
| | Төзелеш, архитектура һәм ТКХ бүлеге | |
| 12. | Башлык | 1 |
| 13. | Баш белгеч | 1 |
| | Мәдәният бүлеге | |
| 14. | Башлык | 1 |
| 15. | Тәрҗемәче (хезмәткәр) | 1 |
| | Икътисад һәм муниципаль заказ бүлеге | |
| 16. | Башлык | 1 |
| 17. | Башлык урынбасары | 1 |
| 18. | Баш белгеч | 1 |
| 19. | Әйдәп баручы белгеч | 1 |
| | Опека һәм попечительлек бүлеге | |
| 20. | Башлык | 1 |
| 21. | Баш белгеч | 1 |
| 22. | Әйдәп баручы белгеч | 1 |
| | Архив секторы | |
| 23. | Мөдир | 1 |
| | Мәгълүмат белән тәэмин итү һәм мәгълүмати иминлек секторы | |
| 24. | Мөдир | 1 |
| | ГХАТ секторы | |
| 25. | Мөдир | 1 |
| | Балигъ булмаганнар эшләре һәм административ практика секторы | |
| 26. | Баш белгеч (балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау буенча комиссиянең җаваплы секретаре) | 1 |
| 27. | Әйдәп баручы белгеч (балигъ булмаганнар арасында гаилә җитешсезлекләрен һәм хокук бозуларны профилактикалау буенча инспектор) | 1 |
| 28. | Административ комиссия секретаре | 1 |
| | Категориядән тыш | |

| | | |
|---|---|---|
| 29. | Автомобиль йөртүче | 4 |
| 30. | Җитәкче сәркатибе | 2 |